КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 6 декабрь г.Казань № 1049

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 234 нче; 2016 ел, 23 июнь, 433 нче; 2016 ел, 14 ноябрь, 840 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1137 нче; 2019 ел, 19 ноябрь, 1049 нчы; 2020 ел, 25 декабрь, 1186 нчы; 2021 ел, 4 ноябрь, 1051 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1441 нче; 2023 ел, 5 июнь, 687 нче; 2023 ел, 9 октябрь, 1279 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен, Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү формасын һәм Татарстан Республикасының алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары тарафыннан Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш

территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешүләр шартлары үтәлешен мониторинглау чаралары, шул исәптән күчмә чаралар үткәрү тәртибен раслау хакында»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен;

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү формасын;

Татарстан Республикасының алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары тарафыннан Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешүләр шартлары үтәлешен мониторинглау чаралары, шул исәптән күчмә чаралар үткәрү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибендә:

7 пунктның «г» пунктчасындагы икенче абзацында «Оешмаларның бухгалтерлык хисаплылыгы формалары турында» 2010 елның 2 июлендәге 66н номерлы» сүзләрен «Бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы» 4/2023 ФСБУ бухгалтерлык исәбе федераль стандартын раслау турында» 2023 елның 4 октябрендәге 157н номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада «Ф.И.Ат.ис.» аббревиатурасын «Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада «Ф.И.Ат.ис.» аббревиатурасын «Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү формасында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү формасы»;

3.3.2 пунктта татар текстында «тулылыгын һәм дөреслеген» сүзләреннән соң «, кирәк булганда, Резиденттан раслый торган документларны сорап,» сүзләрен өстәргә;

3.5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.12. Килешү шартларының үтәлешен тикшерүдә тоту өлешендә Министрлыкка һәм Башкарма комитетка ярдәм итәргә, шул исәптән Министрлык, Башкарма комитет, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары һәм федераль башкарма хакимият органнарының вазыйфаи затларына Резидентныкы булган һәм алгарышлы үсеш территориясендә урнашкан инфраструктура объектларына тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә;»;

әлеге формага 2 нче кушымтада «Ф.И.Ат.ис.» аббревиатурасын «Ф.И.Ат.ис.

(соңгысы – булганда)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга Татарстан Республикасының алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары тарафыннан Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешүләр шартлары үтәлешен мониторинглау чаралары, шул исәптән көчмә чаралар үткәрү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

«______________________________________________»
(алгарышлы үсеш территориясе исеме)

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә (аңа үзгәреш кертүгә)
заявка

Теркәлгән һәм үз эшчәнлеген бары ______________________________ муниципаль
(муниципаль берәмлек исеме)
берәмлек территориясендә гамәлгә ашырган ____________________________________
(юридик зат исеме)
_______________________________________________________________ нигезендә эш итүче
______________________________________________________________________ йөзендә
(вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))
«_________________» алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә (аңа үзгәреш кертүгә) заявка җибәрә һәм «Россия Федерациясендә алгарышлы үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алгарышлы үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 елның 22 июнендәге 614 номерлы карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «__________________» алгарышлы үсеш территориясе төзү турында» ________елның ________ _____ номерлы карары таләпләренә җавап бирә торган инвестиция проектын гамәлгә ашыру ниятен раслый.

Заявкага таләп ителә торган материаллар теркәлә.

Белешмәләрнең дөреслеген гарантиялим.

Кушымта: ____________________________________________________________________

Җитәкче: __________ ________________________________ ______________
(имза) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (дата)

М.У. (булганда, гади электрон имза кулланылганда мөһер таләп ителми).

___________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 4 февраль, 61 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 6 декабрь, 1049 нчы
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасының алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары тарафыннан Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешүләр шартлары үтәлешен мониторинглау чаралары, шул исәптән күчмә чаралар үткәрү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алгарышлы үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 елның 22 июнендәге 614 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасының алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары тарафыннан Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешүләр шартлары үтәлешен мониторинглау чаралары, шул исәптән күчмә чаралар (алга таба шул ук эзлеклелектә – резидент, Килешү, Чара) үткәрү механизмын билгели.

2. Чаралар үткәрү өчен алгарышлы үсеш территориясе төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән расланган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү формасының (алга таба – Килешү формасы) 3.5.12 пункты кысаларында, Килешү шартлары үтәлешен контрольдә тоту өлешендә Татарстан Республикасының алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары тарафыннан Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешүләр шартлары үтәлешен мониторинглау чаралары, шул исәптән күчмә чаралар үткәрү комиссиясен (алга таба – Комиссия) төзи. Комиссия әгъзалары – Башкарма комитет, шул исәптән муниципаль районның (шәһәр округының) җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палаталары (идарәләре), муниципаль районның (шәһәр округының) финанс-бюджет палатасы (финанс идарәсе), Чаралар үткәрү өчен катнашырга кирәк булган үз компетенциясе кысаларында башка органнар, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы вәкилләре; шулай ук түбәндәгеләр, Килешүнең бер ягы

белдергән теләккә карап, катнашучылар буларак түбәндәгеләр җәлеп ителергә мөмкин: Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, эшчәнлек өлкәсе Чаралар үткәрелә торган алгарышлы үсеш территориясе резидентының инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла торган икътисадый эшчәнлек төренә караган республика башкарма хакимият органнары вәкилләре (алга таба шул ук эзлеклелектә – чакырылган вазыйфаи затлар, республика башкарма хакимият органнары).

3. Чаралар үткәрү кысаларында резидент (юридик зат җитәкчесе яки резидентның вәкаләтле вәкиле) эшчәнлеге Килешү шартларына туры килү-килмәве билгеләнә.

4. Чаралар план буенча яки планнан тыш, күчмә яки читтән торып үткәрелергә мөмкин.

5. План буенча чаралар муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан расланган һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килештерелгән план (алга таба – Чаралар планы) нигезендә үткәрелә. Чираттагы календарь елга Чаралар планы агымдагы ел тәмамланганга кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча раслана.

Чаралар планында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Чаралар үткәрелә торган юридик зат – резидент исеме;

б) Чаралар үткәрү урыны;

в) Чаралар үткәрү предметы;

г) тикшерелә торган чор;

д) Чаралар үткәрү срогы (Чаралар үткәрелә башлау һәм тәмамлан даталары).

6. Чаралар планына кертелмәгән Чаралар үткәрү планнан тыш булып тора. Планнан тыш чаралар Башкарма комитет тарафыннан юридик затлардан, гражданнардан, шул исәптән индивидуаль эшмәкәрләрдән, дәүләт хакимияте органнарыннан резидентның Килешү шартларын бозуы турында язма белешмәләр алынган очракта, шулай ук резидентның алдагы Чаралар нәтиҗәләре буенча ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләрне үтәвен тикшерү яки мониторинглау максаты белән үткәрелә.

7. Һәр резидентка карата Чаралар үткәрү Башкарма комитет җитәкчесенең тиешле карары (алга таба – Чараларны үткәрү турында карар) белән рәсмиләштерелә, анда әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы «а» – «д» пунктчаларында күрсәтелгән мәгълүматлар, шулай ук Комиссия әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) һәм вазыйфасының тулы исеме күрсәтелә.

8. Чаралар үткәрелә башланган датага кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, резидентка (юридик зат җитәкчесенә яки резидентның вәкаләтле вәкиленә) Чаралар үткәрү турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) җибәрелә, анда түбәндәгеләр бирелә:

а) Чаралар үткәрү турында карар;

б) Чаралар уздыру өчен резидент тарафыннан тапшырылырга тиеш булган, тикшерелә торган чор өчен резидент эшчәнлеген характерлый, шулай ук резидент тарафыннан капитал салулар гамәлгә ашырылуын раслый торган документларның әлеге Тәртип кушымтасы нигезендә исемлеге (алга таба – Чаралар үткәрү өчен документлар).

Күчмә Чаралар үткәргәндә, Чаралар үткәрү урынына килгәч, Комиссия резидентка Чаралар үткәрү турында карар күчермәсен, аңа имза куйдырып, тапшырырга

тиеш.

9. Чаралар үткәрү срогы иң күбе 14 календарь көн тәшкил итә. Катлаулы һәм (яки) озак тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү зарурлыгы белән бәйле искәрмәле очракларда, Чаралар үткәрү срогы Чаралар үткәрү турында карар нигезендә, әмма иң күбе 14 календарь көнгә озайтыла.

10. Чаралар үткәргәндә Комиссия әгъзалары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

а) Чаралар үткәрү срокларын үтәргә;

б) Чаралар үткәргәндә резидентны аның хокуклары һәм бурычлары белән таныштырырга;

в) резиденттан алынган документларның төп нөсхәләре саклануын һәм аңа кире кайтарылуын тәэмин итәргә;

г) резидентның банк, салым яки коммерция серен тәшкил иткән һәм Чаралар үткәрү барышында Комиссия әгъзаларына билгеле булган мәгълүматларның конфиденциальлеген сакларга;

д) Чараларны, резидентның җитештерү процессын бозмыйча, оештырырга һәм үткәрергә;

е) резидентны Чаралар үткәрү нәтиҗәләре белән таныштырырга.

11. Комиссия әгъзалары үз компетенцияләре чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Чаралар үткәргәндә ысулларны һәм гамәлләр тәртибен мөстәкыйль билгеләргә (алгарышлы үсеш территориясендә резидент тарафыннан башкарыла торган эшчәнлек үзенчәлекләреннән чыгып);

б) Чараларны үткәрү өчен документлар таләп итәргә һәм алырга;

в) Чаралар үткәрүгә каршы тору, шул исәптән Комиссия әгъзаларына дөрес булмаган, тулы булмаган мәгълүмат тапшыру яисә аны үз вакытында тапшырмау, тикшерүчеләр алган мәгълүматтан рөхсәтсез файдалану фактларын теркәргә;

г) резидент тарафыннан Килешү шартлары үтәлүен бәяләү максатыннан чыгып, резидентныкы булган һәм АҮТдә урнашкан, шул исәптән төзелә һәм реконструкцияләнә торган АҮТнең инфраструктура объектларын (алга таба – АҮТнең инфраструктура объектлары) карарга (кирәк булганда фотога һәм видеога төшереп).

12. Чаралар үткәрелгәндә резидент түбәндәгеләргә бурычлы:

а) Чаралар читтән торып үткәрелгән очракта – хәбәрнамә алынган көннән алып 10 календарь көн эчендә, күчмә Чаралар үткәрелгән очракта – Чаралар үткәрелә башлаган датага Чаралар үткәрү өчен документларны әзерләргә һәм Комиссия әгъзаларына бирергә.

Чаралар читтән торып үткәрелгән очракта, Чаралар үткәрү өчен документлар яки аларның таныкланган күчермәләре Башкарма комитетның рәсми электрон почта адресына җибәрелә. Күчмә чаралар үткәрелгән очракта, резидент Чаралар үткәрү өчен документларның төп нөсхәләрен Комиссия әгъзаларына танышырга тәкъдим итә;

б) Комиссия әгъзаларына җир кишәрлегенә һәм АҮТнең инфраструктура объектларына тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә.

13. Резидент (юридик зат җитәкчесе яки резидентның вәкаләтле вәкиле) Чаралар үткәргәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Чаралар үткәргәндә катнашырга;

б) Чаралар үткәрү предметына караган мәсьәләләр буенча комментарийлар һәм аңлатмалар бирергә;

в) Чаралар үткәрү акты белән танышырга һәм аның буенча дәлилләнгән каршы фикерләрне (кирәк булган очракта), тиешле документларны теркәп, язма рәвештә бирергә;

г) Комиссия әгъзаларының гамәлләренә карата Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә шикаять бирергә.

14. Чаралар үткәрү нәтиҗәләре буенча, алар тәмамланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Комиссия тарафыннан Чаралар үткәрү акты (алга таба – Акт) төзелә, ул түбәндәгеләрне үз эченә ала:

а) кереш өлеше, анда түбәндәгеләр бирелә:

Акт төзү датасы һәм урыны;

Чаралар үткәрү турында карар датасы һәм номеры;

Комиссия әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булганда) һәм вазыйфалары;

Чаралар үткәрелә торган резидент турында мәгълүматлар (юридик зат исеме);

Чаралар үткәрү срогы һәм урыны;

тикшерелә торган чор;

резидентның (юридик зат җитәкчесе яисә резидентның вәкаләтле вәкиле) Акт белән танышуы яисә танышудан баш тартуы турында билгеләмәләр;

элеккеге үткәрелгән Чаралар йомгаклары буенча ачыкланган бозуларны бетерү (бетермәү) фактлары;

б) төп өлеш, анда түбәндәгеләр бирелә:

АҮТдә резидентның башкарыла торган эшчәнлек төрләре тасвирламасы;

АҮТнең инфраструктура объектларын карау нәтиҗәләре тасвирламасы (кирәк булганда фото, видеосурәтләрне теркәп);

Килешү шартлары үтәлмәү фактлары (ачыкланганда);

«Россия Федерациясендә алгарышлы үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473 номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алгарышлы үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 елның 22 июнендәге 614 номерлы карарында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 карарында каралган, Башкарма комитет тарафыннан судка килешүне өзү турында гариза җибәрү өчен нигез булып тора алган башка хәлләр;

в) резолюция өлеше, анда үткәрелгән Чараларның факттагы нәтиҗәләрен бәян итүне, ә ачыкланган бозулар булган очракта, Актта чагылыш тапкан бозуларны раслый торган документларга сылтама бирелә.

Актка түбәндәгеләр теркәлә:

Акт күчермәсе;

үткәрелә торган Чараларга кагылышлы, шул исәптән, бозулар ачыкланган

очракларда, бозулар фактларын раслый торган яки кире кага торган белешмә кәгазьләре, аңлатмалар, башка документлар яки аларның күчермәләре.

15. Дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр булган актлар дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләр үтәлешен саклап рәсмиләштерелә.

16. Акт өч нөсхәдә төзелә һәм Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Актның беренче нөсхәсе резидентка хәбәрнамә белән заказлы хат итеп җибәрелә яки, кул куйдырып, үзенә тапшырыла.

17. Резидент (юридик зат җитәкчесе яки резидентның вәкаләтле вәкиле), Акт белән танышканнан соң, аның барлык нөсхәләренә имза һәм дата куя, «акт белән таныштым, үткәрелгән Чаралар нәтиҗәләре белән килешәм» дип яза. Резидент (юридик зат җитәкчесе яки резидентның вәкаләтле вәкиле) Актка имза куюдан баш тарткан очракта, Актта тиешле билге ясала.

18. Акт нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, резидент Актны алган көннән алып җиде календарь көн эчендә үзенең каршылыклы фикерләрен Башкарма комитетның рәсми электрон почта адресына җибәрә. Аларны карап тикшерү нәтиҗәләрен Башкарма комитет аларны алган көннән алып җиде календарь көн эчендә резидентның электрон почтасына җибәрә.

19. Резидентка Чаралар үткәрү нәтиҗәләренә карата шикаять бирү өчен бирелгән срок чыкканнан соң биш эш көне эчендә Башкарма комитет түбәндәгеләрне җибәрә:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына – Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы (алга таба – ДӘБВС) ярдәмендә, шулай ук Комиссия рәисе имзасы куелган, ияртүле хат теркәлгән кәгазь чыганакта Актның икенче нөсхәсен;

республика башкарма хакимият органнарына – Актлар кергән көннән алып биш календарь көн эчендә чакырылган вазыйфаи затлар тарафыннан имзалана һәм Башкарма комитет адресына җибәрелә торган Актлар күчермәләрен.

Актның өченче нөсхәсе Башкарма комитетта кала.

Актка карата республика башкарма хакимият органнарыннан язма искәрмәләр кергән очракта, Комиссия тарафыннан бирелгән искәрмәләргә бәяләмә әзерләнә . Чакырылган вазыйфаи затларның искәрмәләрен һәм алар буенча бәяләмә Комиссия тарафыннан Актка теркәлә һәм Чаралар үткәрү материалларына кертелә.

20. Чаралар үткәрү нәтиҗәләре буенча килешү формасының 4.1.1 пункты нигезендә җитди дип танала торган бозулар ачыклану Башкарма комитет тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 карары белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә турында килешү төзү тәртибенең 45 пункты нигезендә Килешүне өзү процедурасы башлану өчен нигез булып тора.

21. Актлар Килешү гамәлдә булу срогы дәвамында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында һәм Башкарма комитетта саклана.

Татарстан Республикасының алгарышлы үсеш территорияләре резидентлары тарафыннан Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алгарышлы үсеш территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешүләр шартлары үтәлешен мониторинглау чаралары, шул исәптән көчмә чаралар үткәрү тәртибенә кушымта

Тикшерелә торган чор өчен алгарышлы үсеш территориясе резиденты эшчәнлеген характерлый торган, шулай ук әлеге резидентның капитал салуларны гамәлгә ашыруын раслый торган документлар

1. Салым органы тарафыннан кабул ителү турында билге куелган бухгалтерлык хисаплылыгы*:

бухгалтерлык балансы;

финанс нәтиҗәләре турында хисап;

бухгалтер балансына һәм финанс нәтиҗәләре турында хисапка кушымталар.

2. Салым тикшерүләре актлары.

3. Инвестиция башкарылуын раслый торган түләү документлары (түләү йөкнамәләре, банк өземтәләре).

4. Чара үткәрү өчен кирәкле мәгълүматлар булу шарты белән контрагентлар белән шартнамәләр (аларга өстәмә килешүләрне кертеп) яки шартнамәләрдән өземтәләр.

5. Башкарылган эшләрне (күрсәтелгән хезмәтләрне) кабул итү турында актлар.

6. Эшкә кабул итү турында боерыклар белән штат расписаниесе.

7. Тикшерү өчен кирәкле мәгълүматлар булу шарты белән проект документациясенә дәүләт экспертизасы, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы яки проект документациясенә дәүләткә карамаган экспертиза һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләткә карамаган экспертиза бәяләмәсе (капиталь төзелеш объектлары булганда).

---

*«Бухгалтерлык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы» 4/2023 ФСБУ бухгалтерлык исәбе федераль стандартында билгеләнгән таләпләр (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2023 елның 4 октябрендәге 157н номерлы боерыгы белән расланган) нигезендә.